КАРАР

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**20 ноябрь 2023 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 18 ноябрендә узган:«2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Төрнәс авыл җирлегенең Төрнәс авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның толл калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы:

1. Төрнәс торак пункты чикләрендә авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм таш җәю;

2.Төрнәс авылында урам утларын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу;

3.Төрнәс авылындагы юлларны сезонлы карап тоту;

4.Төрнәстә су белән тәэмин итү чыганакларын норматив хәлгә китерү (янгын гидрантлары өчен коелар, скважиналарны лицензияләү).

5. Тагылмалы янгын сүндерү су сыешлыгын сатып алу;

6. Бакча, Мәктәп, Үзәк урамнарын төзекләндерү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 764 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 404 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 238 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 166 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныырга.

2. 2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Төрнәс авыл җирлегенең Төрнәс авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның толл калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм

алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы:

1. Төрнәс торак пункты чикләрендә авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм таш җәю;

2.Төрнәс авылында урам утларын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу;

3.Төрнәс авылындагы юлларны сезонлы карап тоту;

4.Төрнәстә су белән тәэмин итү чыганакларын норматив хәлгә китерү

(янгын гидрантлары өчен коелар, скважиналарны лицензияләү).

5. Тагылмалы янгын сүндерү су сыешлыгын сатып алу;

6. Бакча, Мәктәп, Үзәк урамнарын төзекләндерү мәсьәләләре буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: С.В. Белов

Төрнәс авыл җирлеге башлыгы С.В.Белов